СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ 27.09.2017

КАРАР № 29-126

с. Большие Меми

Олы Меми авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, Олы Меми авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Олы Меми авыл җирлеге Советының 20.09.2017 ел, № 28-123 карары, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Олы Меми авыл җирлеге башлыгының 20.09.2017 ел, № 6 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

- Олы Меми авылы территориясендә урнашкан 200 метр озынлыктагы Я. А. Гаврилов урамнарына, 50 метр озынлыктагы Яшьләр урамына, 100 метр озынлыктагы Заречная урамына өлешчә вак таш салу
- Олы Меми авыл җирлеге территориясендә Заборная Поляна авылында урнашкан чишмә коймасын тоту

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина